# Ураза гәете

# عيد الفطر

ALSARHAAN.COM

من أهم مقاصد التشريع في الإسلام اجتماع القلوب والمودة والإخاء بين المسلمين ،

**Шәригатьнең иң әһәмиятле максатларыннан булып тора, ул да булса мөселманнарны бер-берсенә кардәшләр итеп, араларында ярату булдырып, йөрәкләрен берләштерү.**

لذلك شرع الله الاجتماع في كثير من العبادات.

**Шуңа күрә Аллаһ Раббыбыз күп гыйбадәтне берләшеп, ягъни җәмәгатьтә башкаруны билгеләгән.**

ومنها صلاة العيد فقد كان النبي صلى الله عليه وسلم يأمر الناس كلهم بالخروج اليها.
حتى أمر النساء الحيّض قائلا: يشهدن الخير ودعوة المسلمين.

Һәм шушы берләшүдән ураза гаете булып тора. Пәйгамбәребез ﷺ барлык кешегә, хәтта күреме булган хатын-кызларга да шушы намазга барып, анда булган хәерлелекне күреп, шушы бәйрәмдә катнашырга әмер итте.

ويستحب الاغتسال والتجمل والتزين لهذا المحفل العظيم.
ويستحب في عيد الفطر ان يفطر على تمرات قبل الذهاب للمصلى

Бәйрәм намазына гөсел алып, матур киемнәр киеп бару, өйдән чыкканчы финик җимешләреннән авыз итү – сөннәт гамәлләреннән булып тора.

فقد كان عليه الصلاة والسلام لا يغدو يوم الفطر حتى يأكل تمرات.

**Пәйгамбәребез ﷺ гает көнне финик җимешләрен авыз итеп, башка бернәрсә дә ашамый торган булган.**

ويبدأ وقت صلاة من ارتفاع الشمس قيد رمح الى وقت الزوال.

**Гает намазының вакыты кояш сөнге биеклегенә күтәрелгәннән бирле зәвәл вакытына кадәр дәвам итә.**

ويستحب أن تصلى في الخلاء او المصلى لا في المسجد ولا بأس بصلاتها في المسجد ؛ اذا لم يتيسر المصلى أو شق الذهاب إليه ولا يستحب لها أذان ولا اقامة.

فقد كان عليه الصلاة والسلام يخرج يوم فطر والأضحى إلى المصلى.

**Аллаһның илчесе ﷺ ике гает намазын да мәчеттән чыгып ачык урында укый торган булган. Шуңа күрә гает намазын мәчеттә түгел, ә ачык урынга чыгып уку Пәйгамбәребезнең сөннәте булып тора, ләкин моңа мөмкинлек булмаса, мәчеттә дә уку рөхсәт ителә. Һәм бу намаз алдыннан азан белән камәт әйтелми.**

فأول شيء يبدأ به الصلاة وصفة صلاة العيد ركعتان.
يكبر في الأولى ست تكبيرات بعد تكبيرة الإحرام والاستفتاح قبل القراءة.

Кешеләр җыелгач иң беренче чиратта намаз укыла, һәм бу намаз ике ракәгатьтән тора. Намазга керү өчен тәкбир әйтелгәннән соң тагын алты тәкбир әйтеп, укый башлаганчы истифтәх догасы әйтелә.

وفي الثانية خمس تكبيرات بعد تكبيرة الانتقال.
ويرفع يديه مع كل تكبيرة. ويكبر الله ويسبح ويحمده بين التكبيرات.

Икенче ракәгатькә тәкбир әйтеп торгач, тагын биш тәкбир әйтелеп тәкбир арасында Аллаһка мактау сүзләре әйтелә. Тәкбир әйткәндә куллар өскә күтәрелә.

ويستحب ان يقرأ في الركعتين بسورتي الأعلى والغاشية أو بسورتي قاف والقمر.

**Ике ракәгатьтә дә Әл-Фәтихә сүрәсен укыганнан соң Әл-Әглә белән Әл-Гашия, я инде Әл-Каф белән Әл-Камар сүрәләрен уку сөннәт гәмәлләреннән булып тора.**

ثم يخطب الإمام بعد الصلاة خطبتين كالجمعة ويستحب للمأمومين حضورها.

**Намаздан соң имам җомга көнендә сөйләгән шикелле килгән кешеләргә хөтбә сөйли, һәм бу хөтбәне тыңлау мөстәхәб булып тора.**

ويستحب للمأموم أن يبكر للمصلى ماشيا.
وأن يرجع من طريق غير الذي أتى منه ويسن لمن فاتته صلاة العيد أن يقضيها على صفتها.

Шулай ук бу көнне гает намазы укыла торган җиргә җәяү килү һәм килгәндә бер юлдан килеп, кайтканда икенче юлдан кайту яхшы гамәл булып исәпләнә. Әгәр берәр кеше бу намазга килә алмаса, сыйфатларына туры китереп бу намазга када кылсын.

لا تكتمل فرحة العيد إلا بطاعة الله تعالى.
وأداء ما أمر به وشرع.

Бу бәйрәмнең шатлыгы бары тик Аллаһка буйсыну һәм Аның әмерләрен үтәү белән генә тулылана.